ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

07 февраля 2020 г.

**КАРАР**

№ 544

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсендәге 1 бүлекнең 23 пункты, «Күмү һәм җирләү эшләре турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсенең 3 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрнең күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эшләре турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче, 2 нче кушымталарда каралганча 6 124,86 (алты мең бер йөз егерме дүрт) сум 86 тиен күләмендә расларга һәм 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Башкарма комитетның « Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2019 елның 21 февралендәге 928 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
544 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, ире (хатыны) булган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 1500,00 |
| 3. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 890,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3734,86 |
| барлыгы | 6124,86 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
544 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлегенә бәяләр
(якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта)

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне төрү | 591,47 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 908,53 |
| 4. Мәетне (калдыкларны) зиратка илтү | 890,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3734,86 |
| барлыгы | 6124,86 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова